ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» июля 2025 ел № 191

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча 2025 елның III-IV кварталына торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 13.07.2007 елның 31 –ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле экспертлык ярдәмен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.12.2024 елның 1210 номерлы карары, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2019 елның 888 номерлы карары нигезендә, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 30.01.2025 елның 33 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» комерцияле булмаган партнерлыгының хатын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның III-IV кварталына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләрне исәпләү өчен торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры хакын 66 000 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәли көче 01.07.2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **И.Х. Салихов**